ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 70 от «10» 03 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен товарлар кайтару, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган муниципаль контрактларга банк хезмәте күрсәтү очракларын билгеләү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 2 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контрактларга банк хезмәте күрсәтү турында» 2014 елның 20 сентябрендәге 963 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен товарлар кайтару, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган муниципаль контрактларга банк хезмәте күрсәтү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контрактларга банк хезмәте күрсәтү турында» 2014 елның 20 сентябрендәге 963 номерлы карары нигезендә расланган контрактларга банк хезмәте күрсәтү кагыйдәләре нигезендә түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

1.1. әгәр контрактның башлангыч (максималь) бәясе, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контракт бәясе кимендә 50 млн. сум тәшкил итсә, контрактны үтәү кысаларында исәп-хисапны мониторинглауны үткәрүдә төзелә торган контрактны банк тарафыннан уздыру;

1.2. күрсәтелгән контрактны үтәү кысаларында башкарыла торган исәп хисап мониторингын үткәрүгә өстәмәләр кертүне күздә тоткан контрактны банк хезмәте күрсәтүгә карата, кабул ителә торган товарларның, эшләрнең (аларның нәтиҗәләренең),контракт шартларына (киңәйтелгән банк тәэмин ителешенә) туры килүен тәэмин итә торган башка хезмәтләр күрсәтүгә карата контракт шартлары, әгәр контрактның башлангыч (максималь) бәясе бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контрактның бәясе кимендә 500 млн. сум тәшкил итсә.

0000011318

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М.Дәрҗеманов